**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№78**
**15.01.2020**

Башкарма комитетның «Гражданнарның аерым категорияләре өчен автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими муниципаль маршрутлар буенча пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру хезмәтләреннән бертигез дәрәҗәдә файдалану мөмкинлеген тәэмин итүгә бәйле алынып бетмәгән керемнәрне кайтару максатында шәһәр бюджетыннан субсидияләр бирү турында» 2020 елның 9 гыйнварындагы 19 номерлы карарының 2 нче кушымтасына үзгәрешләр кертү хакында

Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24, 5.25 пунктлары нигезендә

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «Гражданнарның аерым категорияләре өчен автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими муниципаль маршрутлар буенча пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру хезмәтләреннән бертигез дәрәҗәдә файдалану мөмкинлеген тәэмин итүгә бәйле алынып бетмәгән керемнәрне кайтару максатында шәһәр бюджетыннан субсидияләр бирү турында» 2020 елның 9 гыйнварындагы 19 номерлы карарының 2 нче кушымтасына, аны кушымтада каралганча яңа редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә.

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы И.А. Сәгыйдуллинага, Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе башлыгы С.Ә. Ситдыйковка йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы И.С. Зуев

Башкарма комитетның
2020 елның 15 гыйнварындагы
78 номерлы карарына
кушымта

Башкарма комитетның
2020 елның 9 гыйнварындагы
19 номерлы карарына
2 нче кушымта

Гражданнарның аерым категорияләре өчен автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими муниципаль маршрутлар буенча пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру хезмәтләреннән бертигез дәрәҗәдә файдалану мөмкинлеген тәэмин итүгә бәйле алынып бетмәгән керемнәрне кайтару максатында шәһәр бюджетыннан субсидия бирү буенча комиссия

| Вазыйфаи затның Ф.И.А.и. | вазыйфа |
|---|---|
| Зуев Илья Сергеевич | комиссия рәисе, Башкарма комитет Җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы, Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасары |
| Ситдыйков Салават Әнәс улы | комиссия рәисе урынбасары, Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе башлыгы |
| Парамонов Максим Геннадьевич | комиссия секретаре, Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе башлыгы урынбасары, транспорт һәм элемтә бүлеге башлыгы вазыйфаларын башкаручы, юл хуҗалыгы бүлекчәсе мөдире |
| комиссия әгъзалары: | |
| Әхмәтҗанов Ленар Илдар улы | Башкарма комитетның хокук идарәсе башлыгы |
| Сәгыйдуллина Ирина Алексеевна | Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы. |

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе Г.К. Әхмәтова